ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

19.04.2019 № 600

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының "Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларга беркетмәләр төзү хокукы бирү турында»гы 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында " 2010 елның 30 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының "Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларга беркетмәләр төзү хокукы бирү турында»гы 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының "Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затларга беркетмәләр төзү хокукы бирү турында»гы 2016 елның 21 гыйнварындагы 91 санлы карарының 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
”1.Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты, Татарстан Республикасының административ хокук бозулар турындагы Кодексының 2.1 (Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы, башка дәүләт органы, җирле үзидарә органы, предприятие, учреждение, башка оешмаларның аталышы һәм үзе турында мәгълүмат урнаштыруга кагылышлы Татарстан Республикасы телләр турындагы законга карата), 2.4-2.8., 2.12.-2.14., 2

нче өлешнең 2.15, 3.2.-3.8., 3.10 (гражданнарга карата), 3.11., 3.14.-3.17., 4.4., 5.1., 5.2., 5.6. (туры килә торган муниципаль берәмлекләр территорияләрендә гамәлгә ашырылучы муниципаль йөк ташуга карата) нчы маддәләрендә каралган административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүне түбәндәге вәкаләтле вазыйфаи затларга йөкли:

- муниципаль контроль бүлеге башлыгы;
- муниципаль контроль бүлегенең баш белгечләре;
- тәртип саклау җәмәгать пунктларының баш белгечләре;
- тәртип саклау җәмәгать пунктларының әйдәп баручы белгечләре».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин